**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы №61 25 сентябрь 2017 ел

Илбәк авылы җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Илбәк авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Илбәк авылы башкарма комитетының 2017 елның 11 сентябрендә чыккан 18 номерлы “Җирле референдум үткәрү турында инициатива белдерү” карары, Илбәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендә чыккан 59 номерлы “Җирле референдум үткәрү турында инициатива белдерү” карары нигезләрендә,

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Илбәк авыл җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча 2017 елның 19 ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Илбәк авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 250 сум күләмендә үзарасалым җыю белән килешәсезме. Үзарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

1) авыл җирлегендә яшәүче балалар һәм яшьләр белән чаралар оештыру һәм үткәрү (Илбәк авылында урнаштыру өчен балалар мәйданчыгы сатып алу, балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу һәм төзекләндерү);

2) авыл җирлеге территориясендә яшәү шартларын яхшыртуны оештыру (Ирекле авылындагы һәйкәл тирәсен койма белән әйләндереп алу, төзекләндерү, һәйкәл өчен табличкалар ясату);

3) Авыл җирлегенә кергән торак пунктларда җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшләрен башкару (Тархан һәм Тырыш авылларындагы юлларга щебенка җәю).

«РИЗА» “КАРШЫ”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат буенча рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәренең http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән башлап үз көченә керә.

Рәис Л.Р .Әсәдуллина